**ГЛАВА
ЛЕНИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. 40 лет Победы д. 32,
с. Ленино, 423181

**ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЕНИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**
Җиңүнең 40 еллыгы урамы, 32,
Ленино авылы, 423181

тел.: (8-4348) 3-44-16, факс: (8-4348) 3-44-10; Lenin.nsm@tatar.ru_

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның 30 сентябре №4

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясына ярашлы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге башлыгы

Карар кабул итте:

1. 2024 елның 16 октябрендә Горшково авыл клубында (Болын ур., 54 йорт) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Горшково авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлеге башлыгы тарафыннан тәэмин ителә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Ленино авыл җирлеге Горшково авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, контракт буенча хәрби хезмәт узучы Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрби хезмәткәрләреннән, мобилизацияләнгәннәрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан һәм алынган акчаларны юнәлтүдән тыш, 2025 елда 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы? түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә::
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (кышкы чорда юлларны кардан чистарту (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), җәйге вакытта юлларны чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу, ягулык-майлау материаллары, бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (материаллар, скважинага павильон сатып алу, урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);

«ӘЙЕ» «ЮК»».

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуция челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында "бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru., «Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Горшково авылы, Күл арты урамы, 35А йорт янындагы мәгълүмат стендында кабул ителгәннән соң 10 эш көне дәвамында игълан итәргә.

5. Әлеге карар аның басылып чыгуыннан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге башлыгы С.Ю.Питеркина